РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» март 2023 ел г. Альметьевск № 481

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 749 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 749 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.8.2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) әгәр реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә кулланылса, 5 өлештә билгеләнгән таләпләрне бозу»;

2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан тәкъдим ителә торган хезмәтләр исемлеге раслана:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият

органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан федераль законнар нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү вәкаләтләренә бирелгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләр исемлеген раслау һәм аларны күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү турында» 2011 елның 06 маендагы 352 номерлы карары белән - башкарма хакимиятнең федераль органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү максатларында күрсәтелгән хезмәтләргә карата;

2) Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты - Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында күрсәтелә торган хезмәтләргә карата;

3) җирле үзидарә органының норматив хокукый акты - җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында күрсәтелә торган хезмәтләргә карата.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172